Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 7**

Юлсубино авылы 28 апрель, 2023 ел

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 маддәсендәге 3 пункты, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсенең дә мирас алуга хокукы булмаса яки мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның берсе дә мирас алмаган булса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, шул ук вакытта икенче варис файдасына мирас алудан баш тартуын берсе дә күрсәтмәсә, физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителү;

2) салым түләүченең – физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Настоящее решение вступает в силу после его официального опубликования и распространяет свое действие на правоотношения¸ возникшие с 1 января 2023 года.

3. Үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 мартындагы «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмәнигезләрен билгеләү турында» 2 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге Советының 2017 елның 12 июлендәге “Җирле салымнар, пенялар һәм әлеге салымнар буенча бурычлар түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында” 4 номерлы карары;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56анчы йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Глава Юлсубинского сельского поселения
Рыбно-Слободского муниципального района
Республики Татарстан ____________________ Х.Х.Гатиятов